**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

11.05.2018 № 184

**Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе һәм вазыйфалар атамалары үзгәрүе белән бәйле рәвештә:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме турында» 2016 елның 7 мартындагы 170 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме (алга таба – эш төркеме) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эш төркеме составыннан М.Р. Гафаровны, В.Г. Шәйхразиевны чыгарырга;

эш төркеме составына кертергә:

Вәлиуллов Рөстәм Фәйзрахман улын – Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасарын;

Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улын – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасарын, аны эш төркеме җитәкчесе урынбасары итеп расларга;

эш төркеме әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Э.Ф. Әхмәтованың – «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары»;

Э.Д. Хиялиевның – «Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча)»;

эш төркеме әгъзасы Г.А. Нигъмәтуллинаның фамилиясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Шәрипова».

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ